**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сарлы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Сарлы авылы №65 "05" сентябрь, 2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының 2019 елның 16 декабрендәге 149-74 номерлы “Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның пенсиягә чыгуына бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү тәртибе һәм күләмнәре турында Нигезләмә хакында” карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның пенсиягә чыгуына бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү тәртибе һәм күләмнәре турында Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы “Иминият пенсияләре турында”гы Федераль закон нигезендә

Сарлы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының 2019 елның 16 декабрендәге 149-74 номерлы “Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның пенсиягә чыгуына бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү тәртибе һәм күләмнәре турында Нигезләмә хакында” карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның пенсиягә чыгуына бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү тәртибе һәм күләмнәре турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 бүлекнең 2.1 пунктында беренче абзацтагы «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» 2001 елның 17 декабрендәге 173-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә картлык буенча хезмәт пенсиясе, яки инвалидлык буенча пенсия билгеләү» сүзләрен «Иминият пенсияләре турында»гы 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча хезмәт пенсиясе, яки картлык буенча вакытыннан алда яисә инвалидлык буенча иминият пенсиясе билгеләү)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә:

http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында да веб-адрес буенча: http://aznakayevo.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Л.М.Хаҗиев